СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫ ИҖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

30 август, 1997ел.
ШИМБӘ

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | № 97 (8109) | Бәясе билгеләнгәнчә

БӘЙРӘМЕҢ БЕЛӘН, ТАТАРСТАН!

Хөрмәтле милләттәшләр!

Бүген, Татарстанның бай тарихында иң якты, иң истәлекле бәйрәмнәрнең берсе. Безнең күпмилләтле республикабыз бәйсезлек турында Декларация кабул иткәнне көннән бирле үтелгән җиде ел вакыт Татарстан республикасы президенты М.Ш.Шәймиев сайлаган политик юлга карата ышанычыбызны нык итте, тотрыклылык, иминлек һәм татулык алып килде, алга куелган социаль-икътисадый һәм мәдәни үсеш программасын үтәү буенча реаль нәтиҗәләргә ирешелде. Шуны алга таба да реформаларның уңышлы итеп тормышка ашуына өмет һәм тирән ышаныч тудыра.

Безнең производство коллективлары - авыл хезмәтчәннәре, шикәрчеләр, нефть чыгаручылар, төзүчеләр, транспортчылар һәм башка һөнәр ияләре туган республикабыз муллыгы өчен Октябрь районы потенциалын баету һәм бөтен яклап үстерү өчен хәлләреннән килгәннең барысын да эшлиләр. 1997 елга икмәк сату бурычын районыбыз игенчеләренең республикабыз суверенитетының 7 еллыгы алдыннан иң беренчеләрдән булып үтәве турында рапорты безнең өчен икеләтә куанычлы.

Хөрмәтле шәһәрдәшләр һәм рәндәшләр, сезне республика көне белән котлап, исәнлек-саулык, татулык һәм гаиләләрегездә иминлек теләп, эшегездә уңышлар һәм кәеф көрлеге юлдаш булсын.

Ф.СИБАГАТУЛЛИН,
халык депутатларының Октябрь район Советы рәисе, район хакимияте башлыгы.

Татарстан! Ак бәхетләр сиңа,
Шатлык нурларында коенасың.
Дулкыннарны ярып - ярып йөзгән
Ап-ак кораб булып тоеласың!

Хөрмәтле хезмәттәшләр!

Безнең алда 1 сентябрь - «Белем көне». Бу яңа уку елы башланган көн генә түгел, ә чын-чынлап үзенчәлекле бөтенхалык бәйрәме. Без, мәгариф хезмәткәрләре аны шундый итәргә тиешбез.

Менә җиденче ел инде безнең республикада «Белем көне» тагын бер күркәм бәйрәм - Татарстанның суверенлыгы көне артыннан килә.

Белем көне дә Татарстанга багышлансын һәм «Туган йортым- гүзәл Татарстан» дип аталсын иде, ә республиканың бар халкы өчен кадерле Ватан- Тыныч- Татулык сүзләре девиз булып торыр.

Бәйрәмдә чәчәкләр белән тулсын, куанычлы авазлар ишетелсен, шигырьләр һәм җырлар яңгырасын! Ул яңа уку елына шатлык белән керү өчен бер баскыч булып торсын.

Бәйрәм белән, хөрмәтле хезмәттәшләр! Сезгә ихлас күңелдән нык сәламәтлек, бәхет, шатлык, түземлелек телим. Ижади уңышлар һәм яңа идеяләр юлдаш булсын.

Хөрмәт белән ТР мәгариф министры
Ф.Ф.ХАРИСОВ.

Шәһәр кышка әзерләнә

Норлат җирле үзидарә Советының махсус утырышы шәһәрнең җылылык - энергетика хуҗалыгының 1997 - 1998 нчы елгы ягу сезонына әзерлегенең торышын тикшерде. Шәһәрнең бу мәсьәләгә мөнәсәбәтле барлык предприятие, оешма һәм учреждение җитәкчеләре катнашында узган утырышта бу хакта җирле үзидарә Советы члены, Норлат җылылык челтәре предприятиесе директоры Р.Р.Хәсәнов белдерүен тыңлап, барлык котельняларны һәм җылылык челтәрен 7 сентябрьгә тулы әзерлеккә китерү өчен җаваплы кешеләрне үз карамакларындагы җылылык хуҗалыгында булган барлык җитешсезлекләрне шул срокка бетерергә мәҗбүр иткән карар чыгарылды.

Утырышны Норлат җирле үзидарә Советы рәисе Р.Г.Билалов алып барды һәм анда чыгыш ясады.

Утырышта район хакимияте башлыгының капиталь төзелеш, транспорт һәм элемтә мәсьәләләре буенча урынбасарлары Н.Б.Мәлеков катнашты һәм чыгыш ясады.

Утырыштан тәфсилле язма газетабызның киләсе санында биреләчәк.

Ашлык - дәүләткә!

Бәйрәмгә иң олы бүләк

Районның тагын ун хуҗалыгы, дәүләткә ашлык сату буенча килешү йөкләмәләрен үтәп, Республикабызның дәүләт суверенитеты игълан ителүнең җиденче еллыгы көненә зур бүләк белән килделәр. Болар - Мичурин исемендәге, Синдряков исемендәге, Муса Җәлил исемендәге, «40 лет Победы», «Чирмешән», «Комбайн», «Заря» хуҗалыклары, РСУ, «Агрохимсервис» һәм МСОның ярдәмче хуҗалыклары.

Район хакимияте, халык депутатларының район Советы президиумы ашлык сату буенча дәүләт заказын вакытыннан алда арттырып үтәгән бу хуҗалыклар хезмәтчәннәрен шушы күркәм казанышлары белән чын күңелдән котлыйлар, аларга табыннарыбыз муллыгы хакына күйган фидакарь хезмәтләре өчен олы рәхмәтләрен белдерәп, быел районыбыз кырларында үстерелгән мул игән уңышын җыеп алуны тиз арада төгәлләүдә түземлелек һәм чыдамлылык, һәммәсенә дә ныклы сәламәтлек, гаиләләренә иминлек, барлык изге эшләрендә яңадан - яңа уңышлар телиләр.

Дәүләт амбарларына барлык хуҗалыклардан да ашлык озату уңышлы дәвам итә.

Уракны төгәлләделәр

«Агропромбанк»ның «Лесная Поляна» ярдәмче хуҗалыгы коллективы районда беренче булып уракны төгәлләде. 351 гектарда үстерелгән бөртекле һәм бөртекле - кузаклы культуралар тулысы белән җыеп алынды. Хуҗалык элеваторга 300 тоннадан күбрәк яхшы сыйфатлы ашлык тапшырып дәүләт заказын икеләтә арттырып үтәде һәм ашлык хәзерләүне әле дә уңышлы дәвам иттерә.

Бер үк вакытта 90 гектарда көзге бодай чәчеп киләсе ел уңышына нигез салып куелды, туңга сөрү кебек мөһим агрочара да җиренә җиткереп алып барыла.

Хакимият башлыгы котлый

Район хакимияте башлыгы Ф.С.Сибагатуллин быелгы урыш-җыю чоры алдынгыларына котлау хатлары җибәрә тора. Ул аларда комбайнчыларны, шоферларны хезмәт жиңүләре белән котлый. Комбайнчылар М.М.Гобәйдуллин («Рассвет» КХАсы), Ә.В.Тәмаев («Кондырча» КХАсы), А.М.Рябов («Төрнәс» КХАсы), Х.К.Кыямов («40 лет Победы» КХАсы), шоферлар Ф.Б.Әхмәтвәлиев («Рассвет» КХАсы) һәм А.Л.Харитонов (ПУ-99), механизатор Х.Х. Мирзаханов («Әлмәт» КХАсы) бу көннәрдә нәкъ шундый хатларны укыдылар.

Яшелчә дә, бал да, үлән дә...

Август азагында район үзәге, күпсанлы укытучылар армиясен үзенә җыя торган бердәнбер көн - мәгариф хезмәткәрләренең август киңәшмәсе көнне үткәрелә торган укучылар ярминкәсе елдан - ел оешканрак төс ала, эчтәлеге байый. Быелгысында, мәсәлән, 40 урта, 3 тулы булмаган урта, 9 башлангыч мәктәп катнашса, болардан тыш тагын 12 мәктәпкәчә учреждение дә сәүдә итте. Сүз уңаенда шунысын да әйтергә кирәк, соңгылары мондый чарада узган ике - өч елда гына катнаша башладылар әле. Бик хуп, димәк, мәктәпләр генә түгел, балалар бакчалары да үзләрен - үзләре яшелчә, җиләк - җимеш белән тәэмин итеп калмыйча, артып калган продукцияләрен халыкка сатарлык мөмкинлек тә табалар.

... И, гөрләде дә бит ул көнне ярминкә. Шәһәрнең 4 нче, ярдәмче интернат - мәктәпләрнең сәүдә палаткалары иртәнге бда ук сәүдә итүгә әзерләр иде инде. Сәгать сигезләргә исә мәйданда сәүдә итүчеләр дә, сатып алучылар да байтак иде. Ә прилавкаларда ниләр генә юк: яшелчә, җиләк - җимеш, табигать хәзинәләреннән - мәтрүшкә, каен себеркесе, төрле үләннәр, хәтта үги ана яфрагына кадәр бар иде. Бал, варенье, балалар кулы белән эшләнгән әйберләр белән дә сәүдә иттеләр балалар. Яңа Иглай, Гәйтән мәктәпләре «сәүдәгәрләре» башкалардан аерылып тордылар: милли бизәкләр белән бизәлгән палаткаларда чиккән калфаклар, милли күлмәкләр кигән чибәр кызлар йөзләре чагылды.

Сүз җаенда шуны да әйтергә кирәк, соңгы елларда укучылар ярминкәсенең сәүдә культурасы үсте. Хәзер товарларын өстәлдән сатучы мәктәпләр саны бармак белән генә санарлык калды. Зәвыклы, үзенчәлекле итеп бизәлгән сәүдә палаткалары, сәүдә стандарты таләпләренә җавап бирүче бәяләкләр, витриналар...

Ярминкәгә йомгак ясаучы комиссия әгъзалары боларның барысын да исәпкә алдылар. Ярминкәдә «иң - иң»нәрне билгеләү өчен товар ассортименты һәм аның күпме сатылуы да мөһим бит. Озак баш ваткаинан соң (жиңүчеләрне билгеләү бик катлаулы) комиссия урта мәктәпләр арасында беренчелекне Биләр Озеро мәктәбенә бирде. 3 миллион 13 мең сумлык 39 төрле товар саттылар алар. Шәһәрнең дүртенче һәм Кычытканлы урта мәктәпләре икенче һәм өченче урыннарны бүлештеләр. Башлангычлар арасында Якты Күл мәктәбе, мәктәпкәчә учреждениеләрдән Югары Норлат балалар бакчасы да ышаныч-лы рәвештә конкурста жиңүчеләр булдылар.

Гомумән, мәктәпләр ярминкәгә барлыгы 41.263 мең сумлык товар алып килгән булсалар, әбәт вакытына шуның 39.763 мең сумлыгы сатылып беткән иде инде.

Р.ГИНЯЕВА.

Рәшит рекордлар куя

Былтыргы урак чемпионы **Рәшит Кәлимулла улы Насыйбуллин** («Алга») быел да кырда вакыт белән исәпләшмичә эшли һәм аңа тәүлеккә мең центнер ашлык суктыру да чик түгел. «ДОН - 1500» комбайны белән ул барлыгы 16.438 центнер ашлык суктырып алды инде.

***

Хафизов исемендәге хуҗалыктан **Александр Егорович Донсков** шундый ук комбайн белән 14.922 центнер ашлык суктырды.

***

МТСның җыелма отрядыннан «Кейс» комбайнчылары **Александр Иванович Виноградов** һәм **Алексей Петрович Федоров** 14.642, **Виктор Михайлович Прохоров** белән **Алексей Сергеевич Белогубов** 14 мең центнер ашлык суктырдылар.

***

Мичурин исемендәге хуҗалыктан **Иван Валериянович Николаев** «Нива» комбайны белән 11169 центнер ашлык суктырды.

РСУның ярдәмче хуҗалыгыннан **Венимамин Николаевич Шмелевның** шундый ук комбайндагы күрсәткече - 9476 центнер.

***

«Кондырча»дан **Әсгать Вәзыйх улы Тямаев** һәм «1 нче Май»дан **Павел Иванович Варламов** «ДОН» комбайннарында 13 нче меңгә исәп ачтылар.

***

«1 нче Май»дан **Анатолий Константинович Марков** Нива» комбайны белән 450 гектар игенне теземнәргә салды.

***

«Киекле» хуҗалыгыннан **Илгизәр Илсуар улы Мингалимов** кырдан ындырга »КамАЗ» машинасында 14 мең центнердан артык ашлык кайтарды.

Эш башында оста торса

Үзгәртеп кору еллары коммунизм төзүчеләрнең сафларын нигезенә кадәр таркатып, «мәңгегә берләшкән» союздаш республикаларны Россидән аерып ташлап, Советлар Союзы өстеннән зилзилә кебек бик тиз генә үтеп киттеләр. Властька килгән демократлар, илне базар икътисады рельсларына күчергән булып, завод - фабрикалар эшен кәйсезләндерделәр, крестьянның нигезен җимерделәр.

Әле ярый Татарстанның башында аек акыллы кешеләр торды һәм тора, шуның нәтиҗәсендә республикада моңарчы бөртекләп туплангган бик күп файдалы нәрсәләрне саклап кала алдылар. Әмма инфляция һәм түләмәүчелек кризисын китереп чыгарган кыргый базар икътисадының кечле басымына берүзе генә каршы тору Татарстанның да тулысынча ук хәленнән килмәде. Матди җитештерүнең кимүе, икътисадый күрсәткечләрнең начараюы кебек күренешләр, аларның темплары Россиядәгедән түбәнрәк булса да, Татарстанны да читләтеп үтмәде. Бөтен искене сайлап - нитеп тормыйча җимерә барып, демократлар бүгенге бөтен бәлаләребезне кү-мәклектән күреп, бигрәк тә шуңа нык басым ясыйлар һәм җәмгыятебездән аның тамырын ук корытуны таләп итәләр. Андый басым, беренче чиратта гомер - гомергә коллектив формаларга (алпавыт хуҗалыгы, община, колхозлар, совхозлар, аренда хуҗалыклары) нигезләнгән авыл хуҗалыгы өстенә төште. Авылда күмәклек - социализм уйлап чыгарган нәрсә түгел, ә Россия халыкларының исән калу өчен көрәшенең төп формаларыннан берсе. Ә аерым хуҗалык исә, тыгызлап бәйләгән себеркедән аерылса аз гына бөгүгә дә бик тиз сына торган нечкә чыбык кебек.

Күрше Киров,Самара һәм башка өлкәләрнең элеккеге алдынгы хуҗалыкларының хәзер эшкәртелми торган басуларының зур өлешен үүп үлән басып китү - моның ачык мисалы. Аларда колхозларны һәм совхозларны көчләп куып таратылар, ә анда - санда барлыкка килгән фермер хуҗалыклары, үз җилкәләренә алган авыр йөкне күтәрә алмыйча, үзләреннән үзләре таркалдылар.

Әмма күмәклек төшенчәсе үзе дә бер генә яклы түгел. Ул үзара татулыкка һәм ирекле-леккә корылганда гына яхшы, ә коллективлар өстән мәҗбүриләп төзелгәндә коллектив членнары арасындагы антагонизм һәм үзара сыешмаучанлык һәрчак коллективның алга баруын тоткарлый. Ирекле нигездә төзелгән коллектив кына иҗат һәм нәтиҗәле хезмәт җимешләре бирә ала.

Россия җирлегендә хәтта фермер хуҗалыгы да зур булмаса да күмәк хуҗалык булырга тиеш. Авыл хуҗалыгын дотацияләү мәсьәләләренә караш шактый томанлы булган Россия шартларында ялгыз фермер аптырашта төртелеп кала: аның бу хәлне ерып чыгуы өчен бернинди дә шартлар юк. Америка фермерының исә кыр һәм фермасындагы барлык технологик процесслар механикалаштырылган - һәм алар барысы да дәүләт субсидияләре исәбенә башкарылган. Ә безнең фермер бөтен эшен диярлек кулдан яки таралып беткән техника белән башкара, ә инде нинди дә булса яңалык кертергә тырыша икән, аның бөлгенлеккә төшәчәге көн кебек, чөнки фермер җитештерә торган продукциягә бәяләр индустрия бәяләренә якын да килми, банк кредитлары кабалалы.

Безнең шартларда Россиянең (билгеле инде, Татарстанның да) авыл хуҗалыгының исән - сау калуының бердәнбер формасы ирекле нигездә төзелгән теләсә нинди күмәк хуҗалыкны саклап калудан, авыл хуҗалыгы предприятиеләрен үзләренең нормативтан тыш табышларын авыл хуҗалыгы производствосына финанс ярдәме күрсәтүгә юнәлдерергә сәләтле индустрия предприятиеләре һәм банк капиталы белән кушылдырудан гыйбарәт.

Октябрь районында шушы хакыйкатьне ныклап үзләштергәннәр. Күп яктан бу үз язмышын авыл хуҗалыгы белән ныклап бәйләгән хакимият башлыгы Фатих Сибагатуллинның армый - талмый тырышуы нәтиҗәсендә мөмкин булган. Күп еллар буе республикада әре авыл хуҗалыгы районы булган Мамадыш районы партия оешмасын, аннан республиканың Авыл хуҗалыгы һәм азык - төлек министрлыгын җитәкләгән Фатих Сәүбәнович авыл хуҗалыгы производствосының исән калуына кагылышлы барлык нечкәләкләрне, шулай ук аны нәтиҗәле үстерү юлларын әйбәт күз алдына китерә һәм шуңа күрә аның фикере Октябрь районының гына түгел, ә бөтен Татарстан авыл хезмәтчәннәре өчен дә абруйлы.

Фатих Сәүбәнович фикеренчә, базар икътисадына күчү шартларында авыл хуҗалыгының исән калуы, дөресрәге авыл хуҗалыгында яуланган җитештерү дәрәҗәсен саклап калу әлек оештырылган күмәк хуҗалык формаларын җимерү исәбенә түгел, ә аларның структурасын уйлап үзгәртү, коллективтагы һәркемнең шәхсән үз хезмәтенең генә түгел, күмәк хезмәтнең дә ахыр нәтиҗәләре белән матди һәм рухи - әхлакый кызыксынучанлыгын, шулай ук социаль тормыш дәрәҗәсен күтәрү исәбенә барырга тиеш.

Ф.Сибагатуллин Россия яки Татарстан авыл хуҗалыгын үстерүнең фермерлык юлын санга сукмый дип уйлау ялгыш булыр иде.

- Мин,- ди Фатих Сәүбәнович,- ул хәрәкәтне тулысынча яклыйм, әмма бу мәсьәләдә нинди дә булса ашыгучанлыкка барырга киңәш итмим. Фермерлар заманы җитмәде әле бездә. Иң әүвәл дәүләт аларның эшчәнлеге өчен шартлар булдырырга, бары шуннан соң гына авыл халкын шушы йөкне үз җилкәсенә салырга кодаларга тиеш. Иң уңган ялгыз фермер да дәүләт ярдәменнән башка юллар салырга, газ кертергә, авылның инфраструктурасын булдырырга сәләтле түгел. Фермерның эшләре ничек кенә көйле бармасын, бөтен хуҗалыкны да чынлап торып алып бару: югары репродукцияле орлыклар һәм нәселле терлек, Татарстаннан яки Россиядән читтә дөнья стандарты таләпләренә җавап бирердәй авыл хуҗалыгы техникасы һәм яңа технологияләр сатып алу аның хәленнән килми. Ә күмәк хуҗалыклар хәзер дәүләт республиканың бөтен авыл хуҗалыгына күрсәтә торган финанс ярдәме кысаларында да моңа сәләтле.

Агымдагы елда район хуҗалыклар, шеф оешмалар һәм бюджет средстволары исәбенә авылга тәгәрмәчле һәм чылбырлы 90 трактор, АКШта чыккан «Кейс» маркалы 10 бөртекле ашлык комбайны сатып алган, районның күпчелек хуҗалыкларында шикәр чөгендерен «Сюкден» француз фирмасы технологиясе буенча җитештерү кертелгән, ел ахырына кадәр «лимузин» токымлы 250 баштан күбрәк нәселле яшь терлек алып кайтарту күздә тотыла. «Кейс» комбайннары җитештерүчәнлек ягыннан үзебезнең «ДОН»нарга караганда өч мәртәбә күәтлерәк һәм уңышны җыйганда югалуын уннарча тапкыр киметәләр, өстәвенә теләсә нинди дымлылыктагы һәм җиргә сыланган игеннәрне дә җыйнап алалар. Гәрчә ул комбайннар берәр миллиард сум торса да, шушы өстенлекләрен исәпкә алганда «ДОН»нарга караганда өч мәртәбәгә арзанракка чыга.«Лимузин» үгезләре исә ике ел симерткәндә уртача 1200 - 1300 килограмм авырлыкка җитә.

Ә һич югы бер америка комбайны яки «лимузин» токымлы үгез сатып алу фермерның хәленнән киләме соң? Юк, әлбәттә. Хезмәт җитештерүчәнлеген 10 тапкыр күтәрергә һәм татлы тамыр уңышын гектарыннан 450 центнерга кадәр җиткерергә мөмкинлек бирә торган француз технологиясен кертү чыгымнарына да фермерның көче җитмәячәк.

Авыл хуҗалыгын реформалаштыру инде тәмамланган диярлә иртә әле, ул эш дәвам итә. Әмма шушы стадиядә дә аның бик нәтиҗәле үткәрелүен билгеләп үтәргә мөмкин. Авыл хуҗалыгын реформалаштыру товар җитештерүчеләрнең үзләренең генә түгел, ә авыл хуҗалыгына хезмәт күрсәтүче барлык предприятиеләр комплексының структурасына һәм оештырылуына да кагыла. Барлык предприятиеләрдә һәм күмәк хуҗалыкларда да хезмәт дисциплинасы, һәр эш участогы өчен җаваплылык кискен күтәрелгән.

Реформалаштыруның нәтиҗәләре әле бар тулылыгында күренмәсә дә, беренче яртыеллык күрсәткечләре генә дә күп нәрсә турында сөйли. Малларны карау һәм ашатуга элеккеге күләмдә үк чыгымнар тотылган шартларда да район терлекчеләре дәүләткә ит сатуның яртыеллык планын 143, сөтнекен 163 процентка үтәделәр. Ит һәм сөт хәзерләү күләмнәре узган елгы дәрәҗәдән берьярым тапкырдан күбрәккә артты. Дәүләт ресурсларына сөт сатуның тулай күләме буенча Октябрь районы хуҗалыклары республикада беренче урынга чыктылар. Районның сөт эшкәртү предприятиесенә тәүлек саен 120 тоннадан күбрәк сөт керә. Районның сөт терлекчелеге нык үскән зона булмавын искә алганда, бу күрсәткеч нигездә сөт җитештерүгә йөз тотучы шәһәр яны районнары өчен сабак булырлык.

Игенчеләр дә терлекчеләрдән калышмый. Агымдагы елда алар авыл хуҗалыгы культураларыннан моңарчы күрелмәгән уңыш үстерделәр. Бигрәк тә бөртекле культуралар уңышы куандыра. 1996 елда бер гектардан уртача 23,6 центнер уңыш җыеп алынган булса, районның баш агрохимигы Х.Морадыймов раславынча, агымдагы елда бу күрсәткеч икеләтә үсәчәк. Шикәр чөгендере плантацияләренең продуктлылыгын да икеләтә арттырырга ниятлиләр. Бу көннәрдә күп хуҗалыкларда бөртеклеләрнең гектарыннан 40 һәм аннан да күбрәк центнер ашлык суктыралар. Әле бу районга бирелгән мәгълүматлар буенча шулай, чынлыкта исә күрсәткечләр тагын да зуррак. Күрәсең, хуҗалык җитәкчеләре әле һаман да бөртекләр уңышын юри киметеп күрсәтү гадәтеннән арына алмыйлар. Аларның күбесе, әгәр уңышны ничек бар шулай күрсәтсәң, элеккечә хуҗалыкның бөтен булган уңышын кырып - себереп алырлар да, маллар саламга гына калыр дип шикләнәләр.

Шикәр чөгендеренә әле үсәсе дә үсәсе, әмма татлы тамырның биологик уңышы инде хәзер үк гектардан 300 центнердан артып китә.

Мондый уңышларның сере гади: туфракны төп һәм чәчү алдыннан эшкәртүне үзвакытында һәм сыйфатлы итеп үткәрү, югары сыйфатлы орлыклар гына чәчү (бөртекле культуралар бары тик аркылыга - буйга гына чәчелде), барлык кырларга да минераль ашлама керту (район тарихында беренче тапкыр бер гектарга тукларда 280 килограмм тәэсир итүчән матдә кергән), барлык чәчүлекләрне чүп үләннәренә һәм авыл хуҗалыгы культуралары корткычларына каршы агу - химикатлар белән эшкәртү. Районның барлык механизаторларына үсемлекләрне саклауның иң гади кагыйдәләрен яңабаштан өйрәткәннәр.

Район хуҗалыкларының басулары буйлап узгач мин күрелгән чараларның нәтиҗәлелегенә үз күзләрем белән ышандым: барлык хуҗалыкларда да диярлек авыл хуҗалыгы культуралары чәчүлекләре чүп үләннәрсез һәм корткычлар белән зарарланмаган диярлек иде. Район хуҗалыкларындагы югары игенчелек культурасын тою өчен Октябрь районына чиктәш Әлки районы һәм Самара өлкәсе хуҗалыкларында булырга кирәк. Аларда бөтенләй башка хәл: басуларны солыча һәм билчән баскан, үсемлекләр һәртөрле авыруларга дучар булган, үсемлекләр сирәк, аларның да җир өстендәге өлеше зәгыйфь үскән.

Район хуҗалыклары кырларына минераль ашламалар бары тик туфрак картограммаларын искә алып кына кертелә. Ашламаларны район арадашчыларны, шул исәптән «Татагрохимсервис» холдинг компаниясен дә читләтеп, турыдан туры химия заводларыннан сатып ала.

- Минераль ашламаларны турыдан - туры кайтарту,- ди «Норлат - Октябрьскагрохимсервис» АҖ генераль директоры Х.Морадыймов,- безгә хуҗалыкларның һәм бюджет средстволарын янга калдырырга,һәм нәкъ безгә кирәкле ашламалар гына сатып алырга мөмкинлек бирә. Без, нигездә, зур эффект бирә торган катлаулы минераль ашламалар сатып алабыз. Ә «Татагрохимсервис» исә ашламаларны үзәкләштерелгән тәртиптә сатып алуны көчләп тага, ашламаларның төрләрен дә һәм формаларын да үзе ничек тели шундыйларын, безнең ихтыяҗларны исәпкә алмыйча, өстәвенә, күтәренке бәяләрдә тәкъдим итә. «Татагрохимсервис» хезмәтләреннән баш тартып без аңа түләнә торган 5 процентлы өстәмәдән котылып кына да 1,75 миллиард сумны янга калдырдык, түмәрләп сатып алу бәяләрендә килешүләр төзү нәтиҗәсендә тагын 4,2 миллиардны оттык һәм шул суммага өстәмә рәвештә күпме минераль ашлама сатып алдык дигән сүз.

Сатып алу - сәүдә бәяләре мәсьәләләрендә без һәрвакытта да авыл хуҗалыгы мәнфәгатьләреннән чыгып эш итәргә, шул ук вакытта чын сәүдәгәрләр булырга тиешбез.

Авыл хуҗалыгы предприятиеләре җитәкчеләренә һәм белгечләренә үзләре җитештергән барлык продукцияне урнаштырганда да чын сәүдәгәрләрчә эш итә башларга вакыт. Әлегә алар шундый караш булмау аркасында сөт, ит, ашлык, шикәр чөгендере һәм башка төр продукцияне урнаштырганда шактый саллы финанс югалтуларына дучар булалар. Базар икътисады җитештерү структурасын һәм мөнәсәбәтләрен генә түгел, әмма безнең торгынлык чоры фикер һәм карашларыбызны да реформалаштыруны таләп итә.

М.ЗАХАРОВ,
ТР Финанс министрлыгының авыл хуҗалыгын һәм азык төлекне финансларга бүлеге башлыгы урынбасары, Татарстан Республикасының атказанган икътисадчысы.

TV

ПОНЕДЕЛЬНИК, 1 СЕНТЯБРЯ
«ТАТАРСТАН»

7.00 - 8.00 "Чулпан"
17.55 Балалар өчен "Тамчы"
18.15 "Бизнес - коктейль"
18.45 "Җиһан"
19.00 "Замандаш" циклыннан "Мин кайттым, әни"
19.30 "Слово депутата"
19.45 Новости
20.00 "Мадам Хабибуллина". Парижские зарисовки
20.20 "Әлли - бәлли - бәү"
20.30 Ретроспектива фильмов режиссера Булата Мансурова. "Бей - Барс".Х/ф.1-я серия
22.20 "Карт - бланш"
22.55 Программа передач

ОРТ

6.00 Телеканал "Доброе утро"
9.00 12.00 15.00 18.00 1.35 Новости.
9.15 18.20 "Девушка по имени Судьба". Сериал.
10.00 "Поле чудес".
11.00 Футбольное обозрение.
11.30 19.35 "Угадай мелодию".
15.20 "Погонщики динозавров".
15.45 Марафон-15.
16.05 Звездный час.
16.40 "Гарри - снежный человек".
17.05 ...До шестнадцати и старше.
17.30 Вокруг света.
19.10 Час пик.
20.00 Программа "Мы".
20.40 Спокойной ночи, малыши!
21.00 Время.
21.40 Программа передач.
21.45"Я шагаю по Москве"Х.ф
23.20 В Россию с любовью.
0.15 Адреса Москвы."Чистые пруды".

"РОССИЯ"

8.00 11.00 14.00 17.00 20.00 23.00 Вести.
8.20 Программа передач.
8.25 17.20 Лукоморье.
8.50 17.45 "Посмотри на себя".
9.00 Православный календарь.
9.05 Сам себе режиссер.
9.35 23.45 "Московские истории"
10.10 19.00 "Санта-Барбара".
11.15 "Телемагазин"
11.30 "Человек на земле"
12.00"Подслушанный разговор" Х.ф
13.20 В тишине московских переулков.
13.55 "Магазин недвижимости".
14.25 Тихий дом.
15.05 "Избранницы"
15.50 Золотая карта России.
16.25 Саратовской губернии - 300 лет.
16.20 "TV-Маркет"
16.30 "И это кино".
18.05 Пульс.
18.40 "Товары - почтой".
18.45 "Проект Арсенал".
20.35 "Высокая кровь". Х.ф
23.35 "Мастер-ралли - 97".
0.15 "Дежурная часть".
0.40 Эх,дороги!

ВТОРНИК, 2 СЕНТЯБРЯ
«ТАТАРСТАН»

7.00 - 8.00 "Чулпан".
18.40 Мультфильмы
18.45,20.45 "Җиһан"
19.00 Программы телестудии Республики
19.20 "Сельские будни"
19.45 Новости
20.00 "Посткриптум"
20.15 "Карт - бланш"
20.40 "Әлли - бәлли - бәү"
21.00 "Бей - Барс". 2-я серия
22.10 "Баскетбол, мы тебя любим"
22.20 "Виртуаль тәэсирләр"
22.55 Программа передач

ОРТ

6.00 "Доброе утро"
9.00 12.00 15.00 18.00 23.50 Новости.
9.15 18.20 "Девушка по имени Судьба". Сериал.
10.00 Программа "Мы".
10.40 Смехопанорама.
11.20 Домашняя библиотека. 11.3019.35 "Угадай мелодию". 15.20 "Погонщики динозавров".
15.45 Кварьете "Веселая квампания".
15.55 Мультитроллия.
16.15 Волшебный мир, или Синема.
16.40 "Гарри - снежный человек".
17.05 ...До шестнадцати и старше.
17.30 Вокруг света.
19.10 "Час пик"
20.00 Тема.
20.40 Спокойной ночи, малыши!
21.00 Время.
21.40 Программа передач.
21.45 "Три тополя на Плющихе"
23.10 "Лучший город Земли"

"РОССИЯ"

8.00 11.00 14.00 17.00 20.00 23.00 Вести.
8.25 17.20 Лукоморье.
8.50 9.05 17.45Мультфильмы.
9.00 Православный календарь.
9.15 "Театр одного художника"
9.35 23.50 "Московские истории"
10.10 19.00 "Санта-Барбара".
11.15 16.10 "Телемагазин"
11.30 "Пульс"
13.55 "Магазин недвижимости".
14.25 Эх,дороги!
15.05 "Избранницы"
15.45 Золотая карта России.
16.15 "TV-Маркет"
16.25 "И это кино".
18.05 "Новое "Пятое колесо".
18.40 "Товары - почтой".
18.45 "Проект Арсенал".
20.35 "Вокзал". Х. ф
22.10 "Добрый вечер"
23.35 "Мастер-ралли - 97".
0.15 Момент истины.
0.45 "Цорк"Х.ф

СРЕДА, 3 СЕНТЯБРЯ
«ТАТАРСТАН»

7.00-8.00 "Чулпан"
18.00 Баскетбол. "Уникс - Локомотив" (Казань)- "Сак" (Москва)
19.45 Новости
20.00 "Посткриптум"
20.15 "Точка опоры"
20.40 "Әлли - бәлли - бәү"
20.45 "Җиһан"
21.00 "Земля Санникова". Х/ф
22.35 "Шәрәфигә иярәп". Истамбул
22.55 Программа передач

ОРТ

6.00 Телеканал "Доброе утро"
9.00 12.00 15.00 18.00 0.05 Новости.
9.15 18.20 "Девушка по имени Судьба".
10.00 Тема.
10.40 В мире животных .
11.25 Домашняя библиотека.
11.30 19.35 "Угадай мелодию".
15.20 "Погонщики динозавров".
15.45 Кактус и К.
15.55 До-ми-соль.
16.15 Зов джунглей.
16.40 "Гарри - снежный человек".
17.05 ...До шестнадцати и старше.
17.30 Вокруг света.
19.10 Час пик.
20.00 "В поисках утраченного ".
20.40 Спокойной ночи, малыши!
21.00 Время.
21.45 "Петровка,38"
23.25"Алексей Каплер.Истории любви".

"РОССИЯ"

8.00 11.00 14.00 17.00 20.00 23.00 Вести.
8.20 Программа передач.
8.25 17.20 Лукоморье.
8.50 17.45 Мультфильмы.
9.00 Православный календарь.
9.05 L-клуб.
9.35 23.50 "Московские истории"
10.10 19.00 "Санта-Барбара".
11.15 "Телемагазин "
11.30 Новое пятое колесо.
12.00 "19 39"Х.ф
13.00 "Колизей"
13.55 "Магазин недвижимости".
14.25 "Ностальгия по Чистым прудам"
14.40 Парламентарий.
15.05 "Избранницы"
15.45 "Золотая карта России"
16.15 "TV-Маркет"
16.30 "И это кино".
17.20 Там-там новости.
18.05 "Две дороги, две судьбы..."
18.40 "Товары - почтой".
18.45 "Проект Арсенал".
20.35 "Менялы". Х.ф
22.10 Добрый вечер.
23.35 "Мастер-ралли - 97".
0.15 "Царская ложа"
0.55 Кафе Обломов.
1.35 "Тбилиси - мой дом"Х.ф

ЧЕТВЕРГ, 4 СЕНТЯБРЯ
«ТАТАРСТАН»

7.00-8.00 "Чулпан"
18.40 Мультфильм
18.45,20.45 "Җиһан"
19.00 "Вопросы из записной книжки"
19.30 "ГАИ - информ"
19.45 Новости
20.00 "ЦУМ приглашает..."
20.05 "Посткриптум"
20.20 "Әлли - бәлли - бәү"
20.25 "Авыл"
21.00 "Яр". Х/ф
22.55 Программа передач

ОРТ

6.00 Телеканал "Доброе утро"
9.00 12.00 15.00 18.00 0.30 Новости.
9.15 18.20 "Девушка по имени Судьба". Сериал.
10.00 "Серебряный шар"
10.40 Клуб путешественников .
11.30 Домашняя библиотека.
11.40 Смак.
15.20 "Погонщики динозавров".
15.45 Остров Чунга-Чанга.
16.15 Лего-го!
16.40 "Гарри - снежный человек".
17.05 ...До шестнадцати и старше.
17.30 Вокруг света.
19.10 Час пик.
19.35 Джентльмен-шоу.
20.05 Моя семья: квартирный вопрос.
20.40 Спокойной ночи, малыши!
21.00 Время.
21.40 Программа передач.
21.45"Огарева, 6"
23.20 "Алексей Каплер.Истории любви".
0.00 "Магия: мир сверхъестественного.

"РОССИЯ"

8.00 11.00 14.00 17.00 20.00 23.00 Вести.
8.25 17.20Лукоморье.
8.50 17.45 Мультфильмы.
9.00 Православный календарь.
9.05 Бесконечное путешествие.
9.35 23.50 "Московские истории"
10.10 19.00"Санта-Барбара".
11.15 "Телемагазин "Квантум".
11.30 "Две дороги, две судьбы"
12.00 "1939" Х.ф
12.55 Кумиры. Николай Симонов.
13.00 "Колизей"
13.55 "Магазин недвижимости.
14.25 Милые тени Арбата.
14.40 "На пороге века".
15.05 "Избранницы"
15.45 "Золотая карта России"
16.30 "И это кино".
18.05 "Люди, деньги,жизнь..".
18.40 "Товары - почтой".
18.45 "Проект Арсенал".
21.35 "Гарри Трейси". Х.ф
22.20 Добрый вечер.
23.35 "Мастер-ралли - 97".
0.15 "Царь Иван Грозный"Х.ф

ПЯТНИЦА, 5СЕНТЯБРЯ
«ТАТАРСТАН»

7.00 - 8.00 "Чулпан"
18.00 "Не забудьте выключить телевизор". Х/ф.(на тат. яз.)
19.25 "Дин һәм тормыш"
19.45,21.45 Новости
20.00 "Посткриптум"
20.15 "В Госсовете Татарстана"
20.40 "Әлли - бәлли - бәү"
20.45 "Җиһан"
21.00 "Җомга көн кич белән"
22.00 "Төзек булсын дөньялар". Алабуга районыннан тапшыру
22.25 "Замандаш" циклыннан
22.55 Программа передач

ОРТ

6.00 Телеканал "Доброе утро"
9.00 12.00 15.00 18.00 23.40 Новости.
9.15 18.20 "Девушка по имени Судьба".
10.05 Моя семья.
10.40 Пока все дома.
11.25 "Играй, гармонь любимая!"
15.20 "Погонщики динозавров".
16.40 "...До шестнадцати и старше".
17.05 "50 х 50".
17.30 "Вокруг света"
19.15 Человек и закон.
19.45 "Поле чудес".
20.40 Спокойной ночи, малыши!
21.00 Время.
21.45 "Наша древняя столица"
23.50 "В Москве проездом" Х.ф
1.15 Пресс-экспресс.

"РОССИЯ"

8.00 11.00 14.00 17.00 20.00 23.00 Вести.
8.25 17.20 Лукоморье.
8.50 17.45 Мультфильм.
9.00 Православный календарь.
9.05 "Аншлаг"
9.35 23.50 "Московские истории"
10.10 19.00 "Санта-Барбара".
11.15 "Телемагазин "
11.30 "Люди, деньги, жизнь...".
11.55 16.10 18.35 Московская панорама.
12.00 "1939" Х.ф
13.10 Репортаж ни о чем.
13.25 "Кумиры"
13.55 "Магазин недвижимости".
14.25 Момент истины.
14.50 "Красная книга"
15.30 "Избранницы"
15.45 Золотая карта России.
16.15 "TV-Маркет"
16.30 "И это кино".
18.05 Дорогие мои москвичи.
18.40 "Товары - почтой".
18.45 "Проект Арсенал".
20.35 "Карьера Димы Горина"Х.ф
22.20 "Добрый вечер"
23.35 "Мастер-ралли - 97".
0.20 "Царь Иван Грозный"Х.ф

СУББОТА, 6 СЕНТЯБРЯ
«ТАТАРСТАН»

7.00 - 8.00 "Чулпан"
17.10 Фильм - детям. "Айболит - 66"
18.45 "Җиһан"
19.00 "Бизнес - коктейль"
19.40 "Из личной жизни"... дома"
19.45 Новости
20.00 "Посткриптум"
20.15 "Баскетбол, мы тебя любим"
20.45 "Әлли - бәлли - бәү"
21.05 "Шаян - шоу"
22.00 "Досье - 02"
22.15 "Без кабызган утлар"

ОРТ

7.00 9.05 "Доброе утро"
9.00 "Три дня в Москве."
10.00 15.00 Новости.
10.15 Домашняя библиотека.
10.30 Лотто "Миллион".
10.35 "Утренняя почта"
11.15 Каламбур.
11.45 Смак.
12.10 Возвращение Третьяковки.
12.40 "Московский трамвай"Х.ф
13.35 Немеркнущая звезда Марии Каллас.
13.55 Очевидное-невероятное.
14.25 "Коренная москвичка"
15.20 Мультфильмы.
16.05 "Америка с М.Таратутой"
16.30 В мире животных.
17.10 "Колесо истории"
18.50 Клуб "Белый попугай".
17.50 "Московских окон негасимый свет"
19.45 "Строго на юг".
20.40 Юбилею Москвы посвящается...
21.00 Время.
21.55 "Покровские Ворота"
0.30 Хоккей. "Лада (Россия)- "ТПС" (Финляндия)

"РОССИЯ"

8.00 Утренний экспресс.
8.55 Мультфильмы.
9.45 "Доброе утро, страна!"
10.25 Театр зверей.
10.55 16.55 21.10 Московская панорама.
11.00 14.00 20.00 Вести
11.15 Вестник потребителя.
11.40 "Москва златоглавая"
12.20 16.05 Двойной портрет.
12.35 Человек на земле.
13.45 Ваш партнер.
14.20 "Арабела возвращается", или Румбурак - король страны сказок"Х.ф
15.20 Наш сад.
15.45 "Прогулки по Замоскворечью"
16.15 "Бесконечное путешествие"
17.00 "Мужчина и женщина"
17.40 "Осенние колокола"
18.55 "Субботний вечер"с Р.Виктюком.
20.35 Сам себе режиссер.
21.10 "Чокнутые". Х.ф
23.05 "Мастер-ралли - 97".
23.20 "Совершенно секретно"
0.15 "Встречная полоса".
0.30 Репортер.
0.45 Программа "А" .
1.40 "Любовные грезы Эдгара М" Х.ф

ВОСКРЕСЕНЬЕ, 7 СЕНТЯБРЯ
«ТАТАРСТАН»

7.00 - 8.00 "Чулпан"
18.00 Мультфильмнар
18.20 "Под созвездием лиры"
19.00 "ТОН"
19.40 "Автокалейдоскоп"
20.00 "Телебуклет"
20.10 "Глубокие пласты". К дню работников нефтяной и газовой промышленности
20.25 "Әлли - бәлли - бәү"
20.35 "Тискәре ир, начар хатыннар" спектакль
22.10 "Сирены"
22.55 Программа передач

ОРТ

8.00 "Три дня в Москве"
9.05 Мультфильмы.
9.55 Спортлото.
10.00 15.00 23.25 Новости.
10.15 "Непутевые заметки"
10.35 Пока все дома.
11.10 Утренняя звезда.
12.00 "Служу России!"
12.30 Играй, гармонь любимая!
13.00 Сельский час.
13.30 "Подводная одиссея команды Кусто".
14.20 Смехопанорама.
15.15 Клуб путешественников.
16.00 "Торжественное богослужение в храме Христа Спасителя"
16.30 Мультфейерверк.
17.25 "Один на один"
18.00 Счастливый случай.
18.50 Футбольное обозрение.
19.25 "КВН-ассорти"
20.00 "Строго на юг".
21.00 Время.
21.35 "Киноафиша"
21.40 "Московские каникулы".
23.35 "Трактир на Пятницкой"Х.ф

"РОССИЯ"

8.00 Утренний экспресс.
8.55 "Торговый дом "Ле Монти".
9.10 "Солти".
9.35 "У всех на устах".
9.50 "Доброе утро, страна!"
10.30 Присяга.
11.00 14.00 Вести .
11.15 Русское лото.
11.55 "Без пяти двенадцать".
12.00 Книжная лавка.
12.25 15.25 21.00 Московская панорама.
12.35 "Оренбургский пуховый платок"
12.50 "Цветаева и Ахматова"
13.30 Свой дом.
13.45 Вестник потребителя.
14.20 "Арабела вовращается, или Румбурак - король страны сказок"Х.ф
15.30 Волшебный мир Диснея.
16.20 "Довгань-шоу".
16.50 Футбол без границ.
17.20 "Под сводами Храма Христа спасителя"
18.45 L-клуб.
19.20 "Аншлаг"
20.00 Зеркало.
21.05 Старая квартира.
1955 год.
22.10 "Уловка-22"
23.05 "Звезда шерифа"Х.ф

Имгәү кичендә

НИГӘ ТИЗ ИСЕРӘСЕҢ, ГҮЗӘЛЕМ?

Ни өчен хатын - кыз алкоголь йогынтысына ирләргә караганда шактый күбрәк һәм тизрәк бирелүчән? Гүзәл затларда була торган алкоголизмның сәбәпләрен өйрәнгән Америка галимнәре шундый нәтиҗәгә килделәр: бу, барыннан да бигрәк, хатын - кыз ашказанының физиологик үзлекләренә бәйле. Хатын - кызда алкогольнең тәэсирен нейтральләштерә торган ферментлар азрак күләмдә була икән. Күп санлы экспериментлар вакытында шул ачыкланды: спиртлы эчемлекләрне бертигез кулланганда, хатын - кызның канында алкоголь ирләргә караганда өчтән бер өлешкә диярлек күбрәк була.

Бразилия статистикасы мәгълүматларына күз салсан, исерткеч эчемлекләр белән мавыгучы хатын - кызларның бавыр циррозына, ирләр белән чагыштырганда, 1,5 тапкыр тизрәк дучар булуына инанасын. Алкогольне системалы куллана башлауның 14 нче елында ук авырый башлый алар (ә ирләр 21 елдан соң).

Америка һәм Италия галимнәренең тикшеренүләре күрсәткәнчә, алкоголь кулланучы хатын - кызларның үз - үзләренә контрольне югалтулары дүрт тапкыр тизрәк башлана. Табиблар ирләрдә алкогольнең 30 процентын нейтральләштерә торган гармон тапканнар.

Финляндиядә алкоголизмга каршы көрәшү өчен бик файдалы карар чыгарылган. Илдә аракы сатып алучыга алкогольнең зарары турындагы мәгълүматлар язылган кечкенә генә брошюра да бирәләр. АКШта исә шешә этикеткаларына болай дип язылган: «Хөкүмәт кисәтә: 1. Баш хирургның фикеренчә, хатын - кызлар йөкле вакытта исерткеч эчемлекләр кулланмаска тиеш. 2. Алкоголь куллану эшегезнең нәтиҗәлелегенә тискәре йогынты ясый, сәламәтлеккә зыян сала».

Ә бездә Сәламәтлек саклау министрлыгы тәмәкенең зыяны хакында искәртә, ә аракы шешәләрендә Американыкы кебегрәк кисәтүле сүзләр күрмисең. Янәсе, акылы булса, һәркем үзе анларга тиеш. Хәер, үгет - нәсихәт белән генә ярдәм итеп булса икән. Эчтеңме - кирәгеңне ал, дигән принцип күбрәк айныта. Мәсәлән, исерек килеш урамда йөргән 30 яшьлек хатынны 80 тапкыр таяк белән суктырырга хөкем иткән. Рейтер агентлыгы Әбү - Дабидан хәбәр иткәнчә, Берләшкән Гарәп Әмирлекләрендә алкогольле эчемлекләр кунакханәләрдә генә сатыла.

Билгеле инде, Россия Гарәп Әмирлеге түгел, эчкән өчен таяк белән дә суктырмыйлар, шулай да уйланырлык нәрсәләр бар. Ә эчүдән котылырга теләүчеләргә ничек ярдәм итәргә? Менә берничә рецепт.

Алкоголизмнан дәвалануда (бигрәк тә хатын - кызлар өчен) хуш исле үләннәр бик файдалы. Элекке заманнарда эчкеченең башына шафран һәм фиалкадан венок ясап кидерткәннәр. Укроп, әрем, тузганак төнәтмәләре эчергәннәр. Лимонның файдасы күптәннән билгеле: лимон согы белән дәвалау хәтта күптәнге алкоголикта да исерткеч эчемлеккә жирәнү хисе уяткан. Мондый дәвалану курсы 18 көн дәвам итә. Беренче көнне бер лимоннан башлыйлар, шуннан соң көн дә бер - ике лимонны өсти баралар, аннары инде шул тәртиптә киметә барып, соңгы көннәрдә бер лимонга калдыралар.

Инглиз табибы Джон Андерннның рецепты менә мондый: 1 өлеш кәбестә согын, 1 өлеш гранат (анар) согын, ярты өлеш алма серкәсен кайнап чыккончы утта тотасың һәм ашау алдыннан берәр аш кашыгы эчәсең.

Сынап карагыз, бәлки ярдәме тияр. Ихтыяр көче булса, әлбәттә, ярдәм итәчәк!

Ә ин яхшы кинәш: спиртлы эчемлек белән мавыкмаска, ин әйбәте - эчә башламаска. Аек башта аек фикер, диләр бит.

(«Ватаным Татарстан» газетасыннан).

Берләшкән Гарәп Әмирлекләрендә суд

Ашарга яраклы гөмбәләр турында

12 мәгълүмат...

1.Ашарга яраклы гөмбәләрдә үсемлекләргә генә түгел, хайван тәнендәге тукымаларга да хас матдәләр бар. Аның күләме һәм, иң мөһиме, тупланышы төрлечә. Ул һава торышына, экологиягә, ел фасылына бәйле. Бигрәк тә кызу, аз яңгырлы, әмма җитәрлек күләмле дымсу һавалы җәйләрдә «хайвани» матдә тупланышы көзге гөмбәләргә караганда ун тапкыр күбрәк. Мәсәлән, мускарин токсины (агулы матдә) 1дән 65 процентка кадәр артырга мөмкин. Бу очракта ашарга яраклы гөмбә дә агулыга әйләнә.

2. Мүскариннан башка, гөмбәләрдә берничә мускаридин, буфотеин кебек агулы матдәләр бар. Токсинның микъдары әлкәннәргә зыянсыз булса да, балалар өчен хәтәр булырга мөмкин.

3. Файдалы матдәләр дә (фенилалант, гистидин, тирозин, триметиланин) кирәгеннән артык күп булганда куркыныч.

4. Хәзерге заманда гөмбәләрдә токсин сыйфатлы холин, нейрин, эрготин, корнутин кебек химик матдәләр табыла. Аз гына күләмдәге кузгалак, синиль, гельвел кислоталары кебек тупланышы югары булган матдәләр үлемгә китерергә мөмкин.

5. Ашарга яраклы гөмбәләрдә җыелган мышьяк, магний, кобальт, марганец балалар өчен куркыныч.

6. Агулану гөмбәләрне ашап 6 - 35 сәгать узгач сизелә башлый.

7. Үткән ел нәкъ шул ук урында үскән гөмбәләр быелгылардан бик нык аерылалар. Тышкы ягында аерымлык булмаса да, матдәләр тупланышы һәм күләме, әлбәттә, үзгәрәчәк.

8. Җәйге гөмбә белән агулану көчлерәк. Икенче урында көзге гөмбәләр тора.

9. Ашказанында һәм эчәклектә гөмбәләрне үзләштерү бара. Агулар белән бавыр көрәшә һәм күп очракта җиңелә.

10. Пешкән, кипкән яисә консервланган очракта да токсиннар калуы ихтимал. Хәтта эшкәртелгән гөмбә дә балалар өчен зыянлы булырга мөмкин.

11. Гөмбә - авыр эшкәртелә торган ризык. Аны бары сау - сәламәт организм гына үзләштерә.

12. Иске гөмбәләрдә, ягъни җыйганнан соң бер тәүлек торган гөмбәләрдә, аксымлы һәм майлы матдәләр таркала. Барлыкка килгән агулар нәтиҗәсендә нерв системасы зарарлана, йөрәк эшчәнлеге какшый, ашкайнату һәм сулыш юлларының функциясе үзгәрә.

(«Шәһри Казан»нан)

ХИКМӘТЛЕ ХӘЛЛӘР

Игезәкләр - ике ата баласы

Испаниянең Гранада шәһәрендә яшәүче 35 яшьлек ир 3 яшьлек игезәк кызларының үзенеке булуына шиге туа һәм ул университет лабораториясенә мөрәҗәгать итә. Нәтиҗәләр испанлының хаклы икәнлеген күрсәтә. Чынлап та аның хатыны хыянәт иткән, ләкин кызларның берсе ирнең үзенеке икән. Табиб Хосе Лоренте хатынның 24 - 72 сәгать эчендә ике ир белән якынлык кылуын раслый.

Акыл картлыкта түгел - яшьлектә

Бөекбритания үзенең акыллы кешеләре белән дан тота. Әмма биредә бик акыллы булып туучылар да бар икән. Коулман Шаттель шундыйлардан. Ул 5 яше тулганчы ук мәктәпкә укырга бара. 2 яшендә ук укырга өйрәнгән, акыллы кызчыкка мәктәптә күңелсез булып тоелган һәм аны 9 яшьлекләр сыйныфына күчергәннәр. Шаттель күпкырлы сәләткә ия: җырлый, бии, музыка, чит телләр өйрәнә.

Туйга чакырулы булсаң, кибеткә кер

Женевада өйләнешүче кияү белән кәләш никахка кадәр берничә туй кибете эшләүләр һәм анда туганнарының, дусларының матди хәлен истә тотып, үзләренә кирәк - ярак әйберләрнең исемлеген калдыралар. Туйга чакыру кәгазендә әлеге исемлек калдырылган кибетнең адресы күрсәтелә. Кунакка чакырылучылар исемлектәге әйберләрне берәм - берәм сатып алалар һәм исемлектә алынган әйбер турысына билге куялар.

Японияда җәен өйләнешү хәерле

Биредә җәй көне өйләнешү күпкә отышлы. Чөнки яз, көз, [illegible]ләрендә туй үткәрү күпкә кыйммәт тора. Әйтик, 90 кешегә исәпләнгән 3 сәгатьлек банкет 30 - 40 мең долларга төшә. Шуңа чит илгә туй сәяхәте дә өстәлә. Анысы - 80 мең доллар.

Альбионда туйга тостер бүләк итәләр

Инглизчә туй - ул хәерчеләндерә торган чара. Бу илдә туй гадәтләре нык саклана һәм төгәл үтәлә. Күп итеп кунак чакырыла, мәҗбүри бүләкләр алына, кабриолет яллана, шампан шәрабе елгадай ага һәм чәчәк диңгезе барлыкка килә. Шуңа ике атналык сәяхәт - «татлы ай» өстәлә. Ул һәрвакыт чит илдә үткәрелә. Бөекбританиядәге туйлар гаҗәеп оешкан төстә тантаналы, күңелле булып уза. Туйда һәр кеше үз ролен белә һәм аны оста итеп башкара. Ханымнар туйга эшләпәдән килә. Кияү егетенең түшенә оста итеп сайланган чәчәк букеты куела, ә кәләш ак атлас туфлидан була.

Инглиз яшьләре 16 яшьтән никахлаша, ләкин мондый күренеш сирәк була.

Бу илдә туйларга хезмәт күрсәтүче зур индустрия эшли. Туй тантанасына чәчәк куючы флористлар, туй шарлары, декорацияләр әзерләүче фирмалар, бары тик туйларга торт җитештерүче кибетләр, туй киемнәрен, җиһазларын, мебельләрен прокатка җибәрүче конторалар эшли. Биредә туй машинасына курчак куймыйлар, ә ленталар бәйлиләр. Ә шәһәр урамнарыннан узганда машиналар каты итеп сигнал биреп бара.

Туйларда 100, 200, 300 кеше була. Моның өчен махсус урын алына, еш кына ул шәһәрдән читтә, чирәм җирдә, уйсу урында, табигать кочагында үткәрелә. 150 кешедән торган һәм арендага алган бинада үткәрелгән туй 2,5 - 3 мең фунт стерлинг (4,5 - 5 мең доллар) тора. Ул югары дәрәҗәдә уза икән, бу сумга тагын бер нуль өстәлә. Яшь өйләнүчеләр бүләккә кухня кирәк - ярагы, савыт - саба алалар, акчалы конвертлар да булгалый. Әмма туй бүләкләре арасында иң киң таралганы - тостер.

(«Мәдәни җомга»дан).

БЕЛДЕРҮЛӘР

Сатабыз

Әйбәт хәлдәге ВАЗ - 21063 автомашинасы. Степан Разин ур., 4 - 7 адресы буенча, кичке 5тән соң мөрәҗәгать итәргә.

***

1996 елның ноябрендә чыккан ВАЗ - 21213 «Нива» автомашинасы. Тел.: 5 - 12 - 50.

***

Стенка өчен яңа көзгеләр һәм пыялалар. Тел.: 2 - 26 - 43.

***

1995 елда чыккан, 5 нче КПП, ВАЗ - 2107 автомашинасы. Адрес: Дружба ур., 76 - 42. Тел.: 65 - 8 - 48.

Алмаштырабыз

10 сутый участогы, гаражы, мунчасы булган мансардлы 5 бүлмәле коттедж Татарстанның теләсә кайсы шәһәрендә 3 һәм ике берәр бүлмәле фатирга. Әфган поселогында 166 нчы позициягә мөрәҗәгать итәргә.

***

Островский урамындагы 41 нче шәхси йорт бер бүлмәле фатирга. Тел.: 2 - 10 - 73 (Таняга), кичке сәгать 6дан соң.

***

Егоркино авылында шәхси йорт Норлатта бер бүлмәле фатирга. 20 сутый бәрәңге бакчасы, яшелчә бакчасы, сарае, мунчасы бар, суы кергән, газ белән ягыла. Тел.: 4 - 02 - 37. Сәг. 1дән 3кә кадәр.

Төрлесеннән

Октябрь районы торак - коммуналь хуҗалыгы МППсында 06 авария диспетчер службасы ачыла. Урамдагы, су - канализация челтәрләрен ремонтлау буенча заявкалар белән 2 - 29 - 68 телефоны буенча мөрәҗәгать итәргә.

***

Равзыева Алия Шакирҗановна исеменә беренче мәктәп тарафыннан бирелгән АС сериясе № 0030923 номерлы аттестатны гамәлдән чыккан дип исәпләргә.

***

Мингалимов Ислам Исхак улы исеменә бирелгән паспорт, хәрби билет, шофер таныклыгын табучыны бүләк бәрабәренә Чулпан авылына китереп бирүен сорыйбыз.

***

Сафронов Владимир Ефимович исемендәге документлары белән сумка табучыны бүләк бәрабәренә Гыйматдинов ур., 60 - 13 адресы буенча китереп бирүегезне сорыйбыз. Тел.: 2 - 22 - 83.

***

Яшь кеше озак вакытка фатир эзли. Тел.: 2 - 10 - 85 (эш).

БАШ МӨХӘРРИР **Р.Ф.ҖАМАЛИЕВ.**

МӨХӘРРИР **С.Н.ХӘЙРУЛЛИНА**

Учредительләр: Октябрь район хакимияте һәм редакциянең хезмәт коллективы.

"Дуслык" район газетасы атнаның чәршәмбе, җомга, шимбә көннәрендә чыга, рус һәм чуваш телләренә тәрҗемә ителә.

Безнең адрес: 423000, Татарстан Республикасы, Норлат шәһәре, Карл Маркс урамы,19.

Телефоннар: баш мөхәррир - 2-12-14, 2-22-81, мөхәррир һәм авыл хуҗалыгы бүлеге - 2-22-51, Советлар һәм җәмәгать оешмалары тормышы, чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-10-44, җаваплы сәркәтип - 2-18-67, рус теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-14-16, бухгалтерия,реклама бүлеге, фотокорреспондент - 2-15-63.

Газета Татарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат Министрлыгында 34 нче номерлы таныклык белән теркәлде.

Ульяновск өлкәсе матбугат һәм мәгълүмат идарәсенең Димитровград типографиясе. Офсет ысулы белән басылды. Күләме - 1 басма табак. Тираж 2334 данә.